**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№5832**
**13.11.2019**

Башкарма комитетның «Муниципаль ихтыяҗлар өчен җир участогын кире алу турында» 2019 елның 14 июнендәге 3025 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Җир кодексының 56.6 маддәсе, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамә нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Муниципаль ихтыяҗлар өчен җир участогын кире алу турында» 2019 елның 14 июнендәге 3025 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) преамбулада «39.22» цифрларын төшереп калдырырга;

2) 3 пунктның 5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) җир участогын кире алу буенча эш йомгаклары буенча җир участогын һәм анда урнашкан күчемсез милек объектын муниципаль ихтыяҗлар өчен кире алу турында килешү әзерләргә.»

2. Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсенә:

1) әлеге карар кабул ителгән көннән башлап 10 көн эчендә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә;

2) әлеге карар кабул ителгән көннән башлап 10 көн эчендә, закон тәртибендә билгеләнгәнчә, әлеге карарның күчермәсен әлеге карарның 1, 2 пунктларында күрсәтелгән кире алына торган күчемсез милек объектларына хокукы булган затларга җибәрергә;

3) әлеге карар кабул ителгән көннән башлап 10 көн эчендә әлеге карарның күчермәсен Татарстан Республикасы буенча Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте идарәсенең Яр Чаллы бүлегенә җибәрергә;

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев